КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 июнь г.Казань № 591

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган 2015 – 2025 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче, 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы, 2017 ел, 30 декабрь, 1140 нчы, 2020 ел, 15 июнь, 490 нчы, 2021 ел, 12 февраль, 73 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2015 – 2025 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

гаризалар бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасын, ул сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннең иртәгесеннән 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

ирешү өчен әлеге Тәртипнең 4.1 пунктында каралган субсидия бирү нәтиҗәсен (алга таба – субсидия бирү нәтиҗәсе);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә эш бирүчеләргә таләпләр һәм әлеге таләпләргә туры килү-килмәвен раслау өчен эш бирүчеләр тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 2.4 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 2.5 – 2.10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

эш бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм төгәлләнү датасы;

сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән, субсидия бирү турында карар кабул ителгән оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба - Субсидия бирү турында килешү) кул куярга тиеш вакыт;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) Субсидия бирү турындагы килешүне төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда, шулай ук рәсми сайтта урнаштыруның сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң була алмаган датасы.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Эш бирүчеләр бердәм порталда, шулай ук рәсми сайтта сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән Министрлыкка бу Тәртипнең нигезләмәләренә аңлатма бирү турында язма соратулар җибәрергә хокуклы. Әгәр

әлеге сорату Министрлыкка сайлап алуда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча кергән булса, Министрлык әлеге сорату кергән көннән биш эш көне эчендә бу Тәртипнең нигезләмәләренә аңлатмаларны язма рәвештә яки электрон документ рәвешендә җибәрә.»;

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яисә террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә, йә аларга карата массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел»;

2.5 пунктның беренче абзацына «, шулай ук рәсми сайтта» сүзләрен өстәргә;

2.8 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Гаризаларын карап тикшерү максатларында, Министрлык тарафыннан гаризаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Комиссия Министрлык хезмәткәрләре арасыннан төзелә. Комиссия составына Министрлык каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре кертелә, шулай ук килешү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы бүтән башкарма органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләре кертелә ала.»;

2.9 пунктта:

өченче абзацта «сайлап алуда катнашучыларны» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «эш бирүче» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. 3.1. Комиссия сайлап алуда катнашу өчен заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә заявка теркәүгә алынганда бирелгән тәртип саны нигезендә, тиешле финанс елына эш бирүчеләргә субсидия бирү өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә сайлап алуда җиңгән һәр эш бирүчегә бирелә торган субсидия күләмен (S) түбәндәге формула буенча билгели:

$$S = N \times C \times P,$$

монда:

S - субсидия күләме, сум;

N - эш бирүчедә эшләүче инвалидлар саны;

C - эш бирүченең инвалидлар хезмәте өчен түләүгә чыгымнарын каплау күләме, бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминиятләштерү кертемнәренә арттырылган Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләме;

P - эш бирүченең инвалидларга хезмәт өчен түләүгә чыгымнарын каплау чоры, айлар.

Комиссия бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта Комиссия утырышының беркетмәсен төзи, анда заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм

урыны, заявкаларның тәртип саннары, заявкалары кабул ителмәгән эш бирүчеләр турында (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп) мәгълүмат; сайлап алуда җиңгән эш бирүчеләр исемнәре (аларга бирелә торган субсидияләр күләмнәрен күрсәтеп) күрсәтелә.

Комиссия утырышының беркетмәсе нигезендә Министрлык, Комиссия утырышының беркетмәсе төзелгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Субсидия бирү турындагы килешү төзелә торган эш бирүчеләрне билгели һәм бердәм порталда һәм үзенең рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән эш бирүчеләр турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән эш бирүчеләр турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

субсидия бирү турындагы килешү төзелә торган эш бирүчеләрнең исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидияләр күләмнәре.»;

3.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән һәм эш бирүчеләрнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;»;

3.2 пунктның беренче абзацында «бердәм порталда» сүзләреннән соң «, шулай ук рәсми сайтта» сүзләрен өстәргә, «1 октябрьгә кадәр» сүзләрен «1 августка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

эш бирүче тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 3.2 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүче тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү;»;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.6 пунктта:

тугызынчы абзацта «4.1 һәм 4.2 пунктлары нигезендә» сүзләрен «4.3 һәм 4.4 пунктлары нигезендә» сүзләренә, «, максатлар» «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрне» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «, максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

3.9 пунктның беренче абзацында «1 декабрьдән дә соңга калмыйча» сүзләрен «15 декабрьдән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Субсидия бирү нәтиҗәсе һәм хисаплылыкка таләпләр

4.1. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе - хисап аеннан соң килүче айның 1 нче

числосына Субсидия бирү турындагы килешүдә каралган инвалидларның эш урыннары санын (кимендә өч эш урыны) саклау.

4.2. Субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Эш бирүчеләр ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең (шартнамәнең) үрнәк рәвешенә кушып бирелә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында Министрлыкка хисап тапшыралар.

4.4. Министрлык Субсидия бирү турындагы килешүдә эш бирүче тарафыннан өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле V бүлек өстәргә:

«V. Субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны (мониторингны) гамәлгә ашыру һәм аларны бозган өчен җаваплылык

5.1. Министрлык эш бирүчеләрнең субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, үтәвен тикшерә. Эш бирүчеләр тарафыннан субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшерү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирүнең нәтиҗәсенә ирешү мониторингын үткәрү, Субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең һәм субсидия (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле проектны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларның күрсәткечләренә ирешүдән чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләр буенча мониторинг үткәрү.

5.2. Субсидияләр Министрлыкның, финанс контроле органының тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә эш бирүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына керемгә түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә - субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган, эш бирүче тарафыннан субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе бозылган очракта, шул исәптән Министрлык, дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракта;

субсидия суммасыннан 1 процент күләмендә – Субсидия бирү турында килешүдә каралган субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешмәгән өчен.»;

5.3. Эш бирүче тарафыннан бу Тәртипнең 5.2 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының алтмыш сигезенче абзацыннан тыш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган 2015 – 2025 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 2.3 пунктындагы өченче абзацның гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин